Reviews

Бәяләмә һәм күзәтүләр

Рецензии и обзоры

# A REVIEW OF THE MONOGRAPH OF A.SH.YUSUPOVA, G.A.NABIULLINA, R.G.MUGTASIMOVA, ETC. *THE TATARS LIVING IN CHINA: LANGUAGE AND FOLKLORE*

**Murat Özşahin,**
Ushak University,
Izmir str. 8.km., 1 September Campus 64200 Ushak/Turkey,
mozsahin35@hotmail.com.

The reviewed monograph provides a survey of the migration history and modern life of Tatars living in China. The Tatar language, which is kept and actively used in diaspora, and its grammar and lexical features are fully investigated and compared with the modern Tatar language, its dialects, language history and other kindred Turkic languages (Uigur, Kazakh) on the practical side. Models of folklore are introduced into scientific circulation.

The reviewer highly appreciates the research of language and folklore of the Tatar diaspora and emphasizes the source study importance of the monograph in studying of life, language and culture of the Tatars living in China.

**Key words**: the Tatars living in China, the Tatar diaspora, language, folklore, language features.

Lately the scientists of the republic of Tatarstan began to pay more attention to the language features of numerous compatriots living not only in the regions of Russia, but also in foreign countries. The complex study of the language features of the Tatar diasporas provides an opportunity to draw serious conclusions for linguistics and the history of the nation. On the one hand, they kept the archaic phenomena of the language of the period when they moved. On the other hand, the language of Tatars living abroad experienced changes under the influence of other languages. As a result, new phenomena have appeared in the language of people living in new socio-political and economic-cultural circumstances. Different research approaches are inspired by the striving to study Tatar speech, which is comprehensively preserved and used in the diaspora. The studies should consider its practical application and its comparison with the modern literary Tatar language and its dialects. They should also ensure a multi-level approach. The volume monograph “The Tatars living in China: the language and folklore” which has just been published is one of those kinds of work.

The Tatars in China presently live integrated with the Uigur and the Kazakh, they speak the old Tatar language and use the Arabic alphabet. Having lived with the Uigur, Kazakh and Chinese peoples for their entire lives, Tatars have been influenced by the languages, traditions and culture of these peoples. The Tatar customs and traditions in their turn could not but have an impact on other

kindred nations. In the end, the language of periphery Tatars experiences different lexical and grammatical changes and development, having been isolated in previous centuries, and has found itself surrounded by the Chinese language, under the influence of "exchange of language, vocabulary and ethics" with the Uigur and Kazakh.

It is quite interesting to study the language of the diaspora that incorporates some lexical and grammatical features of the Uigur, Kazakh, Chinese and Russian languages, but has saved the historical and modern features of the Tatar language. But it is necessary to say that nowadays China has put a lot of effort into studying the cultures of the minor nationalities. That is why there is a book to be released in China that includes information about Tatars, their customs, households, holidays and their sayings. It has been written by the Tatars living there. There are many papers, researches and newspaper articles written about Tatars living in China. Books like "Brief history of the Chinese Tatars", "Tatar national songs", "Tatar poetry", "Story of the Chinese Tatars", "Chinese Tatars memoir" have already been printed and released for the public.

Concerning the monograph, the main objective is to learn the history, language, religion and folk art of Tatars living in China and in the cities of Kuldzha and Urumqi, in particular. The book is based on the expedition to the Kuldzha and Urumqi cities by the teachers and students of the Kazan Federal University. The book includes examples from folk writings and everyday language. The theoretical and scientific part is based on the works of such Tatar scientists and linguists as M.Z.Zakiev, D.G.Tumashev, F.S.Safiullin, D.B.Ramazanov, F.S.Bayazitov, F.U.Yusupov, F.M.Khisamova and such famous turcologists as N.A.Baskakov, N.Z.Gadzhiev, B.A.Serebrennikov and G.A.Abdurakhmanov. While learning about the history, culture and language of the Chinese Tatar diaspora, the authors have also studied works and articles by M.Gosmanov and M.Chanyshev.

Firstly, the monograph briefly reviews the history and culture of the Tatar diaspora living in China. The authors take a look at all the reasons why Tatars had to move to China, their distribution and the rise of their culture, science and education and evaluate the way they managed to remain Tatar today and how well they use the Tatar language.

The work mainly focuses on the grammar and lexical features of the speech and language of Tatars living in China. It analyses the diaspora's speech, the use of main and auxiliary parts of speech and their formation and changes, the modern Tatar literary language and the dialects, and the history of the language, in comparison with other Turkic people languages – Kazakh and Uighur, in particular.

The diaspora's speech truly shows the grammatical features of the Old Tatar language, on the one hand, and the structural and grammatical features of the Uighur and Kazakh, on the other. Thus, we might come to the conclusion that the language of our fellow countrymen is influenced both by its inner resources and other Turkic languages.

The monograph pays particular attention to the lexical and semantic peculiarities of the language. It thoroughly analyses the use and distribution in the Turkic languages and semantics of the words of various themes (relationship, everyday life, nature, food, animals, plants and birds).

The interesting thing is that the main lexical bulk of the diaspora consists of old, out-of-date and obsolete Tatar literary language word units, and these words are actively used by Tatars living in China. In the paper, some of the lexical units are considered as historical words in the Tatar literary language. They are included in the dictionaries, but are rarely used and considered archaic (*ләшкәр, lashkar – army troops, төман, toman – a gathering place for people*). It is clear now that Tatars living in China use many words that are considered dialectic in the Tatar literary language and nowadays these words are used in Middle, Western and Eastern dialects of the Tatar language.

Learning the origins of lexical units is basic in the study of the historical relations of the diaspora with other languages and the linguistic exchange with them. So it was a great chance to gather and study the borrowings from Arab, Persian, Russian-European and Chinese. The borrowings were divided into various thematic groups: religious terms, scientific terms, socio-political terms, military and medical terms, everyday life and household words, flora and fauna, food items, etc. The number of Russian-European borrowings in the language is explained by social-political changes in the lives of Tatars living in China. Most of the borrowings from Russian and European languages refer to words in everyday life. According to the studies, the Chinese borrowings in Tatar usually refer to socio-political and military spheres, education, and science. The reason for this is that Chinese fiction, scientific literature and mass media have all played a great role in the history of Tatars.

The work focuses on collecting and analysing the folklore and traditions of Tatars living in China. A large number of Tatars, who have moved to China for different reasons, appear to originate from the Kazan Tatars. At the same time, their living close to Uighurs resulted in the acquisition of some family traditions and folklore related to Uighur culture.

When it comes to samples of folk art, it is clear that through the sayings, legends, beliefs and songs found in the monograph, the Tatars living in China still preserve their nationality and traditions and teach them to new generations.

According to the authors, "even though they aspire to save their culture and language, China's Tatars are subject to the assimilation process. They are forced to constantly be in the state of switching from one culture and language to another. By speaking Tatar (being grammatically correct, speaking fluently, and using language units appropriately), they preserve and cherish Tatar traditions and values which is especially characteristic of the older generations of China's Tatars".

In conclusion, it is necessary to say that the monograph "Tatars living in China: language and folklore" makes a major contribution to the studies of the diaspora's language and history. The factual material was checked and thoroughly analysed. It is the first time that the folklore models, described in the monograph, have been used in scientific research. The lexicology and grammar-related material from the monograph are also valuable for studying the history of language, historical grammar, and historical lexicology.

In a word, the paper includes the first research in Tatar linguistics on the language of China's Tatars, particularly its lexical-grammatical features and folklore models. While analysing and studying the linguistic features, the authors focus on the historical features of the current spoken language, Tatar dialects, and languages of the local Turkic people – Uighur and Kazakh.

It is gratifying that the Tatar language is still in use in China. It is most important to properly study the language and introduce the results and discoveries in Tatar linguistics. The studies serve as a basis for getting a full picture of the Tatar people living abroad and their lifestyle. The study of Eastern Tatar diasporas, exemplified by China's Tatars and Tatars living in the Shenzhen-Uighur area, is crucial to current linguistic investigations, as the features of Tatar-Uighur and Tatar-Chinese bilingualism need further research. Consequently, we believe that this research will enable the development of a new theoretical scientific trend in Tatar Language Studies.

# «КЫТАЙДА ЯШӘҮЧЕ ТАТАРЛАР: ТЕЛ ҺӘМ ФОЛЬКЛОР / Ә.Ш.ЮСУПОВА, Г.Ә.НӘБИУЛЛИНА, Г.Р.МӨГЪТӘСИМОВА Һ.Б.» (КАЗАН: КАЗАН УН-ТЫ НӘШР., 2014. 344 Б.) МОНОГРАФИЯСЕНӘ БӘЯЛӘМӘ

**Мурат Өзшаһин,**
Ушак университеты,
Төркия, 64200, Ушак ш., Измир ур., 8 км, 1нче сентябрь кампусы,
mozsahin35@hotmail.com.

Бәяләнә торган хезмәттә Кытайда яшәүче татарларның мөһаҗирлек тарихына, хәзерге яшәешенә гомуми күзәтүләр ясала, диаспорада сакланып калган һәм актив кулланылышта булган татар сөйләме һәм аның лексик-грамматик үзенчәлекләре хәзерге татар әдәби теле һәм аның сөйләшләре, тел тарихы, тугандаш төрки телләр (уйгыр, казах телләре) белән чагыштырма планда фәнни-гамәли яктан комплекслы тикшерелә, халык авыз иҗаты үрнәкләре гыйльми әйләнешкә кертелә.

Бәяләмә авторы Мурат Өзшаһин монография авторларының татар диаспорасы теле һәм фольклор өлкәсендәге тикшеренүләренә югары бәя бирә һәм әлеге хезмәтнең, Кытайда яшәүче татар халкының тормыш-көнкүреше, теле һәм мәдәнияте турында күзаллау тудыру өчен, төп чыганак булып торуын ассызыклый.

**Төп төшенчәләр**: Кытайда яшәүче татарлар, татар диаспорасы, тел, фольклор, тел үзенчәлекләре.

Соңгы елларда Татарстан Республикасында, Россия төбәкләрендә генә түгел, дөнья буйлап сибелеп яшәүче күп санлы милләттәшләребезнең тел үзенчәлекләрен өйрәнүгә дә җитди игътибар юнәлтелә башлады. Чит төбәкләрдә яшәүче татар диаспораларының тел үзенчәлекләрен төрле яклап өйрәнү тел белеме фәне һәм халык тарихы өчен дә әһәмиятле нәтиҗәләр ясарга мөмкинлек бирә. Берьяктан, алар, төп халкыннан аерылып, күчеп китсәләр дә, шул чорның телен, архаик күренешләрен бүгенге көндә дә саклыйлар. Икенче яктан, читтә яшәүче татарлар сөйләме башка телләр тәэсирендә үсеш-үзгәреш кичергән. Нәтиҗәдә, башка иҗтимагый-сәяси, икътисади, мәдәни шартларда яшәгән халыкның сөйләмендә яңа күренешләр барлыкка килгән. Диаспорада сакланып калган һәм кулланылышта булган татар сөйләмен, хәзерге татар әдәби теле һәм аның сөйләшләре, тугандаш төрки телләр (уйгыр, казах телләре) белән чагыштырып, фәнни-гамәли яктан комплексклы өйрәнүгә омтылыш галимнәрне төрле алымнар белән тикшеренүләргә этәрә, һәм төрле яссылыкта эзләнүләр өчен мөмкинлекләр ача. Әле күптән түгел генә дөнья күргән «Кытайда яшәүче татарлар: тел һәм фольклор» дип аталган шактый зур күләмле монография – нәкъ менә шундый тикшеренүләрнең берсе.

Кытайда яшәүче татарлар бүгенге көндә, уйгыр һәм казахлар белән катнашып, аралашып яшиләр, иске татар сөйләм телен һәм гарәп графикасын кулланалар. Гомер буе уйгыр, казах, кытай халыклары белән бергә яшәп, аларның теле, гореф-гадәтләре, мәдәнияте дә татарларга үз йогынтысын ясаган. Шулай ук татар гореф-гадәтләре дә үз чиратында башка кардәш халыкларга тәэсир итми калмаган. Нәтиҗәдә, перифериядәге татарларның теле, узган гасырларда аерымланып, кытай теле чолганышында калып, уйгырлар һәм казахлар белән «тел, лөгать вә әхлак алмашу» тәэсирендә лексик-грамматик яктан күптөрле үсеш-үзгәреш кичереп яши.

Уйгыр, казах, кытай һәм рус телләренә хас лексик-грамматик үзенчәлекләр белән чуарланган, шул ук вакытта татар теленең тарихи билгеләрен, хәзерге татар теле өчен кызыклы тел күренешләрен саклаган әлеге диаспора сөйләмен өйрәнү кызыклы. Шуны да искәртергә кирәк: бүгенге көндә Кытайда илдәге аз санлы халыкларның мәдәниятен өйрәнүгә шактый игътибар бирелә. Шушы уңайдан Кытайда татарлар, аларның риваятьләре, гаилә-көнкүреш йолалары, бәйрәмнәре, беркадәр мәкаль-әйтемнәре тупланган басма әзерләнүе билгеле. Аны шунда яшәүче татарлар әзерләгән. Кытайда яшәүче татарлар турында гыйльми эзләнүләр, фәнни хезмәтләр язылган һәм газета-журналларда мәкаләләр басылган. «Кытай татарларының кыскача тарихы», «Татар халык җырлары җыентыгы», «Татар шигырьләре», «Кытай татарлары турында кыйсса», «Кытай татарлары тәзкирәсе» кебек китаплар басылып, халыкка җиткерелгән.

Бәяләү объекты итеп алынган монографиягә килгәндә, биредә төп максат итеп Кытайда, аерым алганда, Голҗада, Өремче шәһәрләрендә яшәүче татарларның тарихын, телен, рухи мәдәниятен, халык авыз иҗаты үрнәкләрен өйрәнү мәсьәләсе куела. Китап Казан федераль университеты укытучылары һәм студентлары тарафыннан 2009-2013 елларда Өремче, Голҗа шәһәрләренә оештырылган экспедиция материалларына нигезләнеп язылган. Чыганак буларак фактик материал, халык авыз иҗаты әсәрләре, җанлы сөйләм теле үрнәкләре алына. Татар галимнәре М.З.Зәкиев, Д.Г.Тумашева, Ф.С.Сафиуллина, Д.Б.Рамазанова, Ф.С.Баязитова, Ф.Ю.Юсупов, Ф.М.Хисамоваларның фәнни хезмәтләре; күренекле тюркологлар Н.А.Баскаков, Н.З.Гаджиева, Б.А.Серебренников, Г.А.Абдурахманов һ.б. хезмәтләре тикшеренүнең теоретик һәм фәнни-методологик нигезен тәшкил итә. Авторларның Кытайдагы татар диаспорасының тарихын, мәдәни тормышын, тел үзенчәлекләрен өйрәнгәндә, М.Госманов, М.Чанышев хезмәтләренә һәм матбугатта басылган язмаларга да таянып эш итүләре уңай тәэсир калдыра.

Монографиядә беренче чиратта Кытайдагы татар диаспорасы тарихына, рухи мәдәниятенә кыскача күзәтү ясала. Катлаулы һәм үзенчәлекле язмышка ия булган татарларның төрле сәбәпләр белән Кытайга күчеп китүләре, таралышы, фән-мәгариф, мәдәният үсеше һәм бүгенге көндә ни дәрәҗәдә татарлыкны саклап яшәүләре, татар теленең кулланылу өлкәләре бәян ителә.

Хезмәттә Кытайда яшәүче татарларның сөйләменә хас грамматик һәм лексик күренешләрне тикшерү төп игътибар үзәгенә куелган. Диаспора сөйләмендә мөстәкыйль һәм ярдәмлек сүз төркемнәренә караган берәмлекләрнең кулланылышы, ясалышы һәм төрләнеше, хәзерге татар әдәби теле һәм аның диалектлары, тел тарихы, җирле төрки халыкларның

теле, аерым алганда, казах, уйгыр телләре белән чагыштырып анализлана.

Чыннан да, диаспора сөйләменә хас грамматик үзенчәлекләр, берьяктан, иске татар теленә хас күренешләрне чагылдырса, икенче яктан, уйгыр, казах телләренең структур-грамматик тәэсирен күрсәтәләр. Нәтиҗәдә, милләттәшләребезнең теле үзенең эчке ресурслары исәбенә, шул ук вакытта башка төрки телләр йогынтысында үзгәрешләр кичергән дигән фикер туа.

Монографиядә сөйләмнең лексик-семантик үзенчәлекләре тикшерелү аерым игътибарга лаек. Төрле тематик төркемнәргә (туганлык, кардәшлек, тормыш-көнкүреш, табигать күренешләре, ризык, үсемлек, хайван, кош-корт атамалары) караган сүзләрнең кулланылыш активлыгы, төрки телләрдә таралышы, семантикасы җентекләп тикшерелә.

Шунысы кызыклы: диаспора сөйләменең төп лексик фондын татар әдәби теле өчен искергән, онытылган, пассивлашкан сүзләр рәтенә күчкән берәмлекләр алып тора һәм алар Кытайда яшәүче татарлар телендә актив кулланылышта йөриләр. Хезмәттә кайбер лексик берәмлекләрнең татар әдәби телендә тарихи сүзләр рәтендә каралуы ассызыклана. Алар – сүзлекләргә теркәлгән, ләкин кулланылыш ешлыклары чикле сүзләр буларак, әдәби телдә тарихи, архаик берәмлек булып саналалар (*ләшкәр – гаскәр, төман – халык тупланган урын*). Кытайда яшәүче татарлар сөйләмендә татар әдәби теле өчен диалекталь булып саналган лексик берәмлекләрнең шактый күп булуы ачыкланган, аларның хәзерге вакытта татар теленең урта, көнбатыш, көнчыгыш диалектларында очравы дәлилләнә.

Лексик берәмлекләрне килеп чыгышы ягыннан өйрәнү диаспора сөйләменең башка телләр белән тарихи бергәлеген, «тел, лөгать алмашы»н билгеләү өчен җирлек булып тора. Бу җәһәттән, гарәп һәм фарсы, рус-европа, кытай алынма берәмлекләрен туплап тикшерү уңышлы хәл ителгән. Алынмалар төрле тематик төркемнәргә берләштереп тикшерелә: дини сүзләр, фәнни терминнар, иҗтимагый-сәяси терминнар, хәрби һәм медицина терминнары, тормыш-көнкүрешкә бәйле сүзләр, үсемлекләр һәм хайваннар дөньясын яктырткан сүзләр, ризык атамалары, вакыт төшенчәсен белдергән сүзләр һ.б. Сөйләм телендәге рус-европа алынмаларының күплеге кытай татарларының иҗтимагый-сәяси, икътисади, мәдәни тормышында барган үзгәрешләр белән билгеләнә. Рус һәм европа телләреннән кергән алынмаларның зур өлеше тормыш-көнкүрешкә мөнәсәбәтле лексиканы тәшкил итүе һәм аларның көндәлек сөйләмдә еш кулланылулары дәлилләнә. Тикшеренүләргә караганда, татарлар сөйләмендә кулланылган кытай алынмалары, нигездә, иҗтимагый-сәяси, мәгариф, фән, хәрби өлкәләргә карыйлар. Моның сәбәбе кытай телендәге иҗтимагый-сәяси, матур һәм фәнни әдәбият, массакүләм мәгълүмат чараларының татарлар тормышында зур роль уйнавы белән аңлатыла.

Бәяләмә бирелә торган хезмәттә Кытайда яшәүче татарларның фольклор үрнәкләрен, бигрәк тә йола иҗатына кагылышлы материалны туплап бирү һәм тикшерү эше зур игътибарга лаек. Төрле сәбәпләр аркасында Кытайга күчеп киткән татарларның күп кенә өлеше этник чыгышлары белән Казан татарлары булуы аңлашыла. Шул ук вакытта уйгырлар белән яшәү, алар белән тыгыз аралашу нәтиҗәсендә, гаилә-көнкүреш йолаларында уйгырларга кагылышлы фольклор күренешләренең дә урын алуы күзәтелә.

Халык авыз иҗаты үрнәкләренә килгәндә, монографиядә тупланган мәкаль-әйтемнәр, сынамышлар, ышанулар, җырлар һәм мифологик легендалар аша Кытайда яшәүче татарларның, бүгенге көнгә кадәр татар традициясенә нигезләнгән фольклор мирасларын саклап, шулар белән үзләренең милли йөзләрен башкаларга күрсәтү, хәзер дә яшь буынга традицион тәрбия бирүләре аңлашыла.

Авторлар фикеренчә, «татар мәдәниятен һәм телен сакларга омтылыш сизелерлек булса да, Кытайдагы татар мөһаҗирләре ассимиляция процессына дучар. Алар даими рәвештә бер мәдәни һәм тел даирәсеннән чит даирәгә күчү халәтендә яшәргә мәҗбүр. Татар телен белүнең дәрәҗәсе (грамматик яктан дөрес, сөйләү рәвеше, тел берәмлекләрен сайлау), билгеле бер дәрәҗәдә татар көнкүреше, йолалары һәм әхлакый кыйммәтләрен саклау Кытайдагы татар диаспорасының өлкән буын вәкилләренә хас».

Нәтиҗә ясап шуны билгеләргә кирәк: «Кытайда яшәүче татарлар: тел һәм фольклор» монографиясе тел белеменең, диаспора тарихының актуаль проблемаларын өйрәнүгә зур өлеш кертә. Фактик материал югары дәрәҗәдә тикшерелгән һәм тирән анализланган, халык авыз иҗаты үрнәкләре беренче тапкыр фәнни әйләнешкә кертелгән. Монографиядәге

лексик-грамматик күзәтүләргә бәйле материаллар тел тарихы, тарихи грамматика, тарихи лексикология өлкәсендә эзләнүләр өчен бай чыганак булуы белән дә кыйммәтле.

Кыскасы, хезмәттә, татар тел гыйлемендә беренче тапкыр, Кытайда яшәүче татарларның сөйләме, аерым алганда, лексик-грамматик үзенчәлекләре, халык авыз иҗаты үрнәкләре лингвистик планда шәрехләнә. Тел күренешләрен тикшерү, анализлау барышында, тел тарихы үзенчәлекләре, җанлы сөйләм теле, татар диалектлары, җирле төрки халыклар – уйгыр һәм казах телләре белән бәйләнештә фәнни-комплекслы күзәтүләр ясалган.

Хәзерге вакытта татар теленең Кытайда да кулланылышта булуы – куанычлы күренеш. Аны төрле яклап өйрәнеп, нәтиҗәләрне һәм табышларны фәнни әйләнешкә кертеп җибәрү зарури. Тикшеренүләр чит төбәкләрдә яшәүче татар халкының тормыш-көнкүреше турында тулаем күзаллау тудыру өчен, төп чыганак булып тора. Көнчыгышта яшәүче татар диаспорасы телен Кытай татарлары, аерым алганда, Шенҗан-Уйгыр автоном районындагы милләттәшләребез сөйләме мисалында өйрәнү бу юнәлештә кирәкле гамәл булып санала, чөнки андагы татар-уйгыр һәм татар-кытай икетеллелеге үзенчәлекләрен үз эченә алган тел материалы өйрәнелмәгән диярлек, шунлыктан бу тикшеренү татар теленең теоретик-гамәли юнәлешен тагын да үстерер дип уйлыйбыз.

# РЕЦЕНЗИЯ НА МОНОГРАФИЮ ЮСУПОВОЙ А.Ш., НАБИУЛЛИНОЙ Г.А., МУГТАСИМОВОЙ Г.Р. И ДР. «КЫТАЙДА ЯШӘҮЧЕ ТАТАРЛАР: ТЕЛ ҺӘМ ФОЛЬКЛОР» (КАЗАН: КАЗАН УН-ТЫ НӘШР., 2014. – 344 Б.)

**Мурат Узшахин,**
Университет Ушак,
Турция, 64200 Ушак, ул. Измир 8 км, кампус 1 сентябрь,
mozsahin35@hotmail.com.

В рецензируемой книге представлена история татарской эмиграции в Китае и ее современное состояние, проводится сравнительный анализ современного татарского языка и его диалектов, а также других тюркских (уйгурского, казахского) языков, рассматриваются лексико-грамматические особенности разговорной речи диаспоры, история языка, введение в научный оборот образцов устного народного творчества.

Автор рецензии дает высокую оценку исследованию языка и фольклора татарской диаспоры и подчеркивает источниковедческую значимость указанной монографии в изучении быта, языка и культуры татар, проживающих в Китае.

**Ключевые слова**: татары, проживающие в Китае, татарская диаспора, язык, фольклор, языковые особенности.